Бәзәкә авыл советында рәис булып түбәндәге иптәшләр эшләгән:
Гыймазетдинов Гыйлфан (1930-1948)
Багаутдинов Касыйм
Гыймазетдинов Гарай
Гыймазетдинов Миннәхмәт
Ямалетдинова Нажия Ахметризаевна
Хәбибуллин Зиннур Сагитович (1968-1971)
Сабитова Мансура Хаматовна
Нәбиуллин Габделхәй (1975-1981)
Гыймашева Рәмзия Муллаяновна
Нуриев Рифкать Габдуллович
Ахметов Кави
Мөхетдинова (Гыймазетдинова) Рәмзия  Гараевна (1985-1987)
Газимов Валирахман Хасанович (1987-1988)
Гимадиев Нуриәхмәт Галиахметович (1989-1991)
Хикматов Раиф Гиниятович (1991-1995)
Гимазетдинов Рәшит Миннахметович
Гиниятуллин Рафис Закиевич
Салимуллина Мансура Хаматовна
Насифуллина (Хабибуллина) Розалия Зинуровна
1958 нче елда Бәзәкә авылы астында нефть ятмасы табыла.
1961нче елда авылга электр уты керә.
1967нче елның көзендә мәктәпнең хәзерге бинасы эшли башлый. Шул елның 2нче октябрендә Мәдәният йорты ачыла. Шул ук 1967-1968 нче елларда авыл урамнарына  су үткәрелә һәм беренче колонкалар куела.
Түбән Кама ГЭСы төзелү нәтиҗәсендә 1978-1979нчы елларда Кама елгасының суы күтәрелә һәм авыл янындагы әрәмә -көтүлекләрне су баса, елга авыл янына кадәр килә.
1979нчы елда авыл урамнарына нефтьчеләр тарафыннан асфальт юл салына.
1986нчы елның 2нче октябрендә “Лэйсэн” балалар бакчасы ачыла.
1989нчы елның октябрь аенда авыл халкы  көче белән  төзелгән  мәчет  эшли башлый.
1978нче елда йортларга газ кертелә башлый.
2014нче елда Татарстан Республикасының “Чиста су” программасы нигезендә авылга су кертелә.